ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**17.07.2017** **59**

пос. Октябрьский

Минималь хезмәт хакы күләме турында.

"Хезмәткә түләүнең минималь күләме турында "Федераль законның 1 статьясына үзгәреш кертү хакында"19.12.2016 ел, №460-ФЗ Федераль закон нигезендә,

Карар бирәм:

1. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә эш вакыты нормасын эшләгән хезмәткәрләргә хезмәт хакын минималь хезмәт хакыннан кимрәк булмаган 7 800, 00 сум күләмендә түләргә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2017 елның 01 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы

Югары Ослан муниципаль районы

Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш. Р. Азизов